ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» сентября 2020 ел № 293

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының контракт хезмәте турында

Гамәлдәге законнарны хокукый анализлау һәм мониторинглау нәтиҗәләре буенча тәңгәлсезлекләрне бетереп, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуны планлаштыруны һәм гамәлгә ашыруны тәэмин итеп, муниципаль норматив-хокукый актны яңа редакциядә бастырып чыгару максатларында, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 38 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетында аерым структур бүлекчә булдырмыйча гына контракт хезмәте төзергә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Баженова Ольга Алексеевнаны контракт хезмәте җитәкчесе итеп билгеләргә.

3. Расларга:
- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының контракт хезмәте турында нигезләмә (1 нче кушымта);
- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының контракт хезмәте составы (2 нче кушымта).

4. “Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының контракт хезмәте турындагы нигезләмәне раслау хакында” 2018 елның 10 маендагы 214 номерлы карарын, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 10 маендагы 214 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының контракт хезмәте турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында” 2019 елның 22 апрелендәге 154 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр закупкалары секторына әлеге карарның 3 пунктында күрсәтелгән составта контракт хезмәтен әлеге карар белән таныштырырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкче вазыйфаларын башкаручы** **И. И. Шәмсетдинов**

Татарстан Республикасы